# КАРАР

**2022 елның 30 ноябре** **№ 28**

**Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Арпаяз авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 24 ноябрендә 13.00 сәгатьтә һәм 19.00 сәгатьтә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Арпаяз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлардан (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Арпаяз авылында Яр буе урамы, 50 йортка видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Арпаяз авылының Яр буе урамында, юлларга вак таш җәеп, чокырларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, җәю, (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү);

- Арпаяз авылына янгын сүндерү гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру (эш һәм хезмәтләр өчен килешү буенча түләү);

- Арпаяз авылы су башнялары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- энергия саклагыч урам утлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү);

- территорияләрне төзекләндерү һәм чистарту, чүп-чар чыгару (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Арпаяз авылында суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау һәм яңаны салу (проект-смета документларын әзерләү, хезмәтләр һәм эшләр өчен килешү буенча түләү);

- коелар, капкачлар һәм су торбалары, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру;

- клуб өчен спорт җиһазлары сатып алу;

- Арпаяз авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм җәй көне территорияне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Арпаяз авылы зираты өчен инвентарь, җиһазлар һәм кирәк-яраклар сатып алу

- Арпаяз авылы клубын ремонтлау (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү) .

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены карары нигезендә: Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә **128** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны **79**.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 79 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Арпаяз авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Арпаяз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлардан (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

«РИЗА» «КАРШЫ» кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Пычак авыл җирлеге башлыгы Г.Ш. Нәфыйков